КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 май г.Казань № 301

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карары белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 14 декабрь, 1228 нче; 2022 ел, 1 август, 739 нчы; 2022 ел, 15 декабрь, 1331 нче; 2023 ел, 6 апрель, 420 нче; 2024 ел, 29 март, 206 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә, әлеге Тәртип кушымтасының 3 бүлегендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | |
|---|---|
| «9. Оешма эшчәнлегенең төп төрләре | Социаль хезмәт күрсәтү, гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау, гаиләгә, аналарга, аталарга һәм балаларга ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек, Россия Федерациясе законнарында каралган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру формаларын үстерүгә булышлык күрсәтә торган чараларны оештыру һәм үткәрү;<br>гражданнарга һәм коммерциягә карамаган оешмаларга түләүсез яки ташламалы нигездә юридик ярдәм күрсәтү, халыкка хокукый аңбелем бирү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау эшчәнлеге;<br>гражданнарның үз-үзләрен тотышының социаль куркыныч рәвешләрен профилактикалау;<br>хәйрия эшчәнлеге, шулай ук хәйрия һәм ихтыярилыкны (волонтерлыкны) оештыру һәм аларга ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек;<br>белем бирү, мәгариф, фән, мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, гражданнарның сәламәтлеген профилактикалау һәм саклау, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, гражданнарның мораль-психологик торышын яхшырту, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек һәм әлеге эшчәнлеккә булышлык күрсәтү, шулай ук шәхеснең рухи үсешенә ярдәм күрсәтү;<br>мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясе һәм интеграциясе;<br>наркотик чараларны яки психотроп матдәләрне законсыз кулланучы затларны медицина ягыннан тернәкләндерү һәм социаль тернәкләндерү, социаль һәм хезмәт ягыннан реинтеграцияләү чаралары;<br>үзеңнекен күрсәтергә: ______________________ |
| | (әлеге исемлектән оешма тарафыннан үзенең уставы нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлекнең иң күбе биш төре күрсәтелә)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин